ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Физкультура-спорт оешмалары халыкның төрле төркемнәре арасында физик культура һәм спортны үстерү эшен оештыруда катнаша, шул исәптән физкультура-савыктыру хезмәтләрен күрсәтә, спортчыларның һәм спорт ярышларында, тренировка чараларында башка катнашучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыра, спортчыларга һәм тренерларга тренировкалар өчен кирәкле шартлар тәэмин итә, шулай ук әлеге затларга спортта югары нәтиҗәләргә ирешүдә бүтән рәвешле ярдәм күрсәтә. Физкультура-савыктыру хезмәтләре күрсәтү төрләре исемлеге һәм аларны күрсәтү кагыйдәләре Федераль закон нигезендә раслана.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 22 июнь
№ 45-ТРЗ